РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

25.02.2021 № 218-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 31 декабрендәге 1617-п номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

“Дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары нигезендә һәм 2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының көтелгән үтәлеш йомгаклары һәм 2021 елга Татарстан Республикасы финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсе уртак коллегиясенең 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы беркетмәсен үтәү йөзеннән, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “Саба муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру нигезләмәсен һәм тәртибен раслау турында” 2016 елның 31 декабрендәге 1617-п номерлы карары белән расланган, Саба муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** Нигезләмәнең 24 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4) пунктча өстәргә:

“4) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу.”;

**1.2.** Нигезләмәнең 33 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4) пунктча өстәргә:

“4) хуҗалык алып баручы субъектта салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле үтәлмәгән бурычлар булган очракта.”.

**2.** Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М. Р. Ишниязов